# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге составына керүче Урта Саба торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

24.11.2021 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 04.10.2019 елның 33 номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында"гы карарына таянып, 2021 елның 24 ноябрендә узган гражданнар җыенында “2022 нче елда “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Урта Саба торак пунктында, яшәү урыны буенча “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Урта Саба торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

– Урта Саба авылының урам юлларын төзекләндерү һәм вак таш белән түшәү буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 90 кеше кертелгән, шуның 54е тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 49 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР ИТТЕ:

1. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Урта Саба торак пунктында халык җыенын үткән дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип таныргa.

2. “2022 нче елда “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Урта Саба торак пунктында, яшәү урыны буенча “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Урта Саба торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Урта Саба авылының урам юлларын төзекләндерү һәм вак таш белән түшәү” карарын кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча һәм җирлектә урнашкан мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Саба шәһәр җирлеге башлыгы Р.М. Хәсәнов